| РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН<br>МУСЛЮМОВСКИЙ<br>МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН<br>**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>НИЖНЕТАБЫНСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ** | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>МӨСЛИМ МУНИЦИПАЛЬ<br>РАЙОНЫ<br>**ТҮБӘН ТАБЫН<br>АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ** |
|---|---|---|

*Юрид.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Нижний Табын, ул. Молодёжная, 10*
*Факт.адрес: 423977, РТ, Муслюмовский район, с. Верхний Табын, ул. Тукая, 19б*
Тел./факс: 8-85556-32874/Элект. адрес: Ntab.Mus@tatar.ru
ИНН 1629003865, КПП 162901001, ОГРН 1061687001166, ОКТМО 92642450


**П О С Т А Н О В Л Е Н И Е № 03-1**

*Югары Табын* *“20” нче февраль, 2019 нчы ел*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы
Түбән Табын авыл җирлегендә
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә
хезмәт күрсәтү бәяләрен раслау турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Җирләү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары, «2019 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү күләмен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2019 елның 24 гыйнвары 32 номерлы карары нигезендә Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлеге Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1.2019 нчы елның 1 нче февраленнән Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 5946 сум 47 тиен күләмендә билгеләргә һәм 1 нче Кушымта һәм 2 нче Кушымта нигезендә гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегенең рәсми сайтында урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

*Башкарма комитет
җитәкчесе вазыйфаларын үтәүче* *С.М. Гыйльманова*

*Мөслим муниципаль районы*
*Түбән Табын авыл җирлеге*
*Башкарма комитеты җитәкчесе*
*вазыйфаларын үтәүче*
*20.02.2019 нчы ел, № 03-1 карарына*
*1нче кушымта*

## Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Түбән Табын авыл җирлегендә 2019 нчы елның 1 нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (*сум.*)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Табут китерү, җирләү өчен кирәкле әйберләр белән тәэмин итү | 3263,44 |
| 3. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 943 |
| 4. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1740,03 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |

*Мөслим муниципаль районы*
*Түбән Табын авыл җирлеге*
*Башкарма комитеты җитәкчесе*
*вазыйфаларын үтәүче*
*20.02.2019 нчы ел, № 03-1 карарына*
*2 нче кушымта*

**Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы**
**Түбән Табын авыл җирлегендә**
**2019 нчы елның 1 нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге**

| **Хезмәт күрсәтү исеме** | **Хезмәт күрсәтү бәясе (*сум.*)** |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Кәфенләү | 891,85 |
| 3. Табут китерү, җирләү өчен кирәкле әйберләр белән тәэмин итү | 2371,6 |
| 4. Үлгән кешенең мәетен (җәсәдләрен) зиратка китерү | 943 |
| 5. Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1740,02 |
| **Барлыгы** | **5946,47** |